МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ДВОРЕЦ ШКОЛЬНИКОВ»
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Принята на заседании
педагогического совета
Протокол № 1
от «31» августа 2023 г.

«Утверждаю»
Директор МБУ ДО «ДШ»
_______________ Гиниатуллин Р.Н.
от «31» августа 2023 г.

**ДОПОЛНИТЕЛЬНАЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ОБЩЕРАЗВИВАЮЩАЯ ПРОГРАММА**
**«Яшь журналист»**

**Направленность:** социально-гуманитарная
**Возраст обучающихся:** 15-17 лет
**Срок реализации:** 2 года

**Автор-составитель:**
Ибраева Расима Ханифовна
педагог дополнительного образования детей

**АРСК 2019**

**Информационная карта образовательной программы**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Учреждение | МБУ ДО «Дворец школьников» Арского муниципального района РТ |
| 2. | Полное название программы | Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа «Яшь журналист» |
| 3. | Направленность программы | Социально-гуманитарная |
| 4. | Сведения о разработчиках | |
| 4.1. | ФИО, должность | Ибраева Расима Ханифовна, педагог дополнительного образования |
| 5. | Сведения о программе | |
| 5.1. | Срок реализации | 2 года |
| 5.2. | Возраст обучающихся | 15--17 лет |
| 5.3. | Характеристика программы:<br>- тип программы<br>- вид программы<br>- принцип проектирования программы | - дополнительная общеобразовательная программа<br>- общеразвивающая<br>- разноуровневая |
| 5.4. | Цель программы | раскрыть творческий потенциал учащихся в сфере журналистики. |
| 6. | Формы и методы образовательной деятельности | Методы: словесные, наглядные, практические.<br>Формы: объяснение, инструктаж, беседа и дискуссии; применение знаний на практике и др.; работа интернет-ресурсами и др.; самостоятельная поисковая и творческая деятельность,круглые столы, дебаты, диспуты. |
| 7. | Формы мониторинга результативности | Контроль усвоения материала проходит в течение всего периода обучения. По теории журналистики:<br>• сбор информации для газеты;<br>• готовит репортаж с места событий;<br>• подготовка вопросов к интервью;.<br>Промежуточная диагностика:<br>• теоретическая подготовка – собеседование,<br>• практическая подготовка – творческая работа.<br>Итоговая диагностика:<br>• практическая подготовка – творческая работа. |
| 8. | Результативность реализации программы | Успешное участие обучающихся в создании газеты.<br>Наличие призовых мест обучающихся в конкурсах и фестивалях муниципального, республиканского, регионального, российского и международного уровней. |
| 9. | Особые условия (доступность для | В программе предусмотрено участие детей с |

| | | |
|---|---|---|
| | детей с ОВЗ) | особыми образовательными потребностями, которым не требуется адаптированная программа, разработанная с учетом особенностей развития ребенка. |
| 10. | Возможность реализации в сетевой форме | В программе предусмотрено использование сетевой или комбинированной формы реализации. |
| 11. | Возможность реализации в электронном формате с применением дистанционных технологий | Форма обучения: очная, но также предусмотрена возможность реализации в электронном формате с применением дистанционных технологий. |
| 12. | Материально техническая база | Столы<br>Стулья<br>Шкаф книжный<br>Ноутбук<br>Компьютер<br>Принтер |
| 13. | Дата утверждения и последней корректировки программы | 31.08.2023 |

## Оглавление

1. Пояснительная записка…………………………………………………………......5
2. Учебный план, ..................................................……………………………………...........7
3. Планируемы результаты освоение программы……………………………………….....10
4. Формы аттестации, оценочные материалы ……………………………………..........11
5. Список литературы…………………………………………………………..…....12

## Пояснительная записка

Дополнительная общеобразовательная общеразвивающая программа *социально-педагогического направления* «Основы тележурналистики и режиссуры» разработана на основе следующих документов:

1. Федеральный закон об образовании в Российской Федерации от 29.12.2012 №273-ФЗ (с изменениями и дополнениями);
2. Федеральный закон от 31 июля 2020 г. № 304-ФЗ «О внесении изменений в Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации» по вопросам воспитания обучающихся»;
3. Концепция развития дополнительного образования детей (утверждена Распоряжением Правительства Российской Федерации от 31.03.2022 №678-р);
4. Федеральный проект «Успех каждого ребенка» в рамках Национального проекта «Образование», утвержденного Протоколом заседания президиума Совета при Президенте Российской Федерации по стратегическому развитию и национальным проектам от 3.09.2018 №10;
5. Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 3.09.2019 №467 «Об утверждении Целевой модели развития региональных систем дополнительного образования детей»;
6. Федеральный закон от 13 июля 2020 г. №189-ФЗ «О государственном (муниципальном) социальном заказе на оказание государственных (муниципальных) услуг в социальной сфере» (с изменениями и дополнениями, вступившими в силу с 28.12.2022 г.);
7. Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 27 июля 2022 г. №629 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам»;
8. Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 5 августа 2020 года № 882/391 «Об организации и осуществлении образовательной деятельности при сетевой форме реализации образовательных программ»;
9. СП 2.4. 3648-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи», утвержденные Постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 28.09.2020 г. №28;
10. Методические рекомендации по реализации дополнительных общеобразовательных программ с применением электронного обучения и дистанционных образовательных технологий (Письмо Министерства просвещения от 31 января 2022 года № ДГ-245/06 «О направлении методических рекомендаций»);
11. «Об утверждении Общих требований к определению нормативных затрат на оказание государственных (муниципальных) услуг в сфере образования, науки и молодёжной политики, применяемых при расчёте объёма субсидии на финансовое обеспечение выполнения государственного (муниципального) задания на оказание государственных (муниципальных) услуг (выполнения работ) государственным (муниципальным) учреждением» (утверждены пунктом 4.1 приказа Министерства образования и науки Российской Федерации от 22.09.2015 №1040);

12. «Методические рекомендации по проектированию и реализации дополнительных общеобразовательных программ в новой редакции. / Сост. А.М.Зиновьев, Ю.Ю.Владимирова, Э.Г.Демина - Казань: РЦВР, 2023.- с.89;
13. Устав МБУ ДО «Дворец школьников» Арского муниципального района РТ;
14. Положение об общеобразовательных общеразвивающих программах МБУ ДО «Дворец школьников» Арского муниципального района РТ от 31.08.2023 г.

Программа белем бирү программасын тормышка ашыруның челтәр формасы принцибы буенча төзелгән. Белем бирү процессы яклары:

1. Арча муниципаль районының «Укучылар сарае» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе – Укучылар төркемен комплектлау, гомуми белем бирү программасын тормышка ашыру, матди-техник база белән тәэмин итү.

2. “ТАТМЕДИА” АҖ филиалы-Арча-информ»

Укучылар өчен сыйфатлы белем алу мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан, дәресләр дистанцион белем бирү технологияләрен һәм электрон ресурсларны кулланып үткәрелергә мөмкин. Мондый формалар дәресләр үткәрүдә уку материалларын җиңел кулланырга мөмкинлек бирәчәк. Ул үз эченә алган цифрлы белем бирү ресурслары (ZOOM, coreapp. Ai, ватсап һ. б.), уку процессының конкрет шартларында, бу дәресләр үткәрүнең төрле дидактик модельләрен берләштерүгә ярдәм итә.

Уйлаган фикереңне матур һәм дөрес итеп башкаларга җиткерә белү - милли культураның бер өлеше. Укучыларның язма һәм телдән сөйләмен үстерү, аларда газета, радио, телевидение теленә карата дөрес мөнәсәбәт формалаштыру балаларның гамәли шөгыльләренә, зәвыкларына, сәләт-мөмкинлекләренә уңай тәэсир итәрлек итеп оештырылырга тиеш. Әлеге “Яшь журналист” электив курс программасы шушыларны истә тотып төзелде. Мондый эшчәнлек укучыларга сөйләм культурасын, иҗади мөмкинлекләрен үстерергә, ана телебезгә кызыксыну уятырга ярдәм итә.

Газета хәбәрчесе булу - журналистикага беренче адым ясау дигән сүз. Ә кем соң ул газета – журналлар хәбәрчесе? Аңа нинди сыйфатлар хас? Хәбәрче тирән белемле, күп мәгълүматлы, үткен һәм җор телле булырга тиеш.

Яшь хәбәрчеләр белән эшләү укытучыдан да иҗади активлык сорый. Мондый эшчәнлек укучыларга сөйләм культурасын, иҗади мөмкинлекләрен үстерергә, татар матбугатына карата кызыксыну уятырга ярдәм итә. Әлеге программа балаларга эстетик тәрбия бирү, аларның үз фикерләвен киңәйтү, аралашу культурасын үстерү, коллективта иҗади эшли белү сәләтен үстерүне күздә тота.

Программа материалы 144 сәгатькә исәпләнелә. Балаларның иҗади мөмкинлекләре һәм яшь үзенчәлекләреннән чыгып төзелә.

Программа төзү өчен, «Тукай якташы» әдәби берләшмәсе җитәкчесе, өстәмә белем бирү педагогы З.М Зарипованың авторлык программасы файдаланылды.

***Программаның максаты:***

Журналист һөнәренең серләренә төшендерү, аның үзенчәлекләре һәм нечкәлекләре белән таныштыру; эзләнүчән шәхес формалаштыру.

***Бурычлары:***

- вакытлы матбугать жанрлары, аның төрләре белән таныштыру;
- газета чыгаруда иң кирәкле булган: тема табу, фактлар туплау, әңгәмә үткәрү серләренә төшендерү;
- газета теле үзенчәлекләрен өйрәтү;
- газета-журналлар басу технологиясе турында мәгълүмат бирү;
- укучының газета жанрларына караган материалларны дөрес итеп язарга өйрәнүләренә ирешү;
- балаларның фикерләү сәләтләрен үстерү, иҗат активлыкларын киңәйтү;
- эстетик зәвык тәрбияләү.

**Максатка ирешү һәм бурычларны үтәү өчен эш методлары һәм формалары:**

- Әңгәмә;
- экскурсия;
- ИКТ кулану (компьютер, интерактив такта, электрон текстлар)

***Эш формалары:***

- Дәрес-конференция;
- мультимедиа презентацияләре;
- тестлар үтәү;
- эшлекле уен;
- диспут;
- әдәби очрашу.

***Көтелгән нәтиҗә.*** Журналист һөнәренең серләрен үзләштерү, аның үзенчәлекләре һәм нечкәлекләрен аңлау һәм иҗат эшенә тартылу.

## 1нче уку елы планы

| Тема | Барлыгы | теория | практика | контроль |
|---|---|---|---|---|
| Кереш дәрес Мониторинг | 2 | | 2 | Мәкалә |
| Нәрсә ул журналистика | 4 | 2 | 2 | Әңгәмә |
| Журналистның профессиональ этикасы | 4 | 4 | | Әңгәмә |
| Журналистның профессиональ морале | 2 | 2 | 2 | Әңгәмә |
| Газета ничек ясала | 34 | | 26 | Гамәли эш |
| Журналистика жанрлары | 42 | 4 | 38 | Язмаларны яклау |
| Эссе язу алымнары | 24 | 8 | 18 | Әсәр яклау |
| Әкият ничек языла | 4 | 1 | 3 | Әсәр яклау |
| Конкурслар. Очрашулар, әдәби кичәләр | 4<br>18 | | 4<br>18 | Чыгыш ясау |
| Йомгаклау. Белемнәрне тикшерү | 6 | | 6 | Мәкалә язу, яклау |
| | 144 | 21 | 124 | |

**“Яшь журналист” мәктәбененең уку программасы эчтәлеге**

**1 нче уку елы**

1 Кереш дәрес. Газета-журнал хәбәрчесе булу яшь кешегә тормышны һәм кешеләрне өйрәнергә һәм тирәнрәк белергә ярдәм итә. Күп кенә язучылар үзләренең иҗат юлын нәкъ менә газета- журналларга язышудан башлап җибәргәннәр. Бу хакта укучыларга аңлатма бирергә, мисаллар китерергә.Балаларнын белем дәрәҗәсен белү өчен тест уздыру.

2. Журналистикага беренче адымнар. Кем ул газета-журналлар хәбәрчесе? Ул нинди сыйфатлары белән башкалардан аерылып тора? Журналист булам дигән кеше үзендә нинди сыйфатлар тәрбияләргә тиеш:

Тирә-яктагы тормыш белән кызыксынучанлык. Мисаллар белән аңлатырга.
Тормышны күзәтә белү кирәклеге. Андагы вакыйгаларны күзәтә, чагыштыра һәм нәтиҗә ясый белү. Мисаллар белән аңлатырга.
Үзен журналист булу өчен бүтәннәргә язганны укып барырга кирәклеге. Тормышны яхшы белү, илдәге вакыйгалардан, сәясәттән хәбәрдән булу зурлыгы. Шуның өстенә, әлбәттә инде матур әдәбиятны укырга һәм андагы яңалыклар белән дә таныш булырга кирәклеге. Үз тәҗрибәмнән әңгәмәләр.

3. Журналист һөнәре өлгерлекне, вакыйгалар һәм яңалыкларны соңа калмыйча, озакка сузмыйча, үз вакында яктыртуны,ягъни газета-журналлар укучыларына соңармыйча хәбәр итүне сорый. Бу хакта да мисаллар белән аңлатырга.

Газета-журналлардан ялган хәбәрләргә, төгәлсезләкләргә, арттыруларга, урын юк. Андагы вакыйгалар,фактлар, кешеләр уйлап чыгара алмый. Барысы да төгәл, дөрес һәм тормыштагыча ' булырга тиеш. Шуңа күрә хәбәрләр язучының намуслы булучы шарт.

4. Кешеләр белән аралаша белү. Үз язмасы өчен мәгълүмат туплаганнар вакытта газета-журнал хәбәрчесенә бик күп кешеләр белән аралашырга,сөйләшергә туры килә. Шуңа күрә ул кешеләр белән аралашу осталыгына да ия булырга тиеш. Кешеләр белән аралашуның, кызыклы һәм җанлы итеп сөйләшүнең үзе бер сәнгать икәнен миссаллар белән аңлатырга.

Башлап язучы журналистлар һәм хәбәрчеләр еш кына язарга тема таба алмыйча аптырыйлар. Темаларны көндәлек тормыш бирә, шул темаларның әһәмиятлесен һәм кызыклысын сайлап ала белергә кирәк.

5. Газета ничек ясала. Ул укучы кулына кергәнче нинди юл уткәнне аңлату. Айга бер тапкыр компьютер аша җыйнап әдәби берләшмәнең иҗади органы “Мәктәп пульсы” газетасын чыгару. “Арча хәбәрләре” газетасы редакциясенә экскурсиягә бару.

6. Бу уку елында журналистларның жанрларын өйрәнергә. Язучының максатларыннан чыгып журналистика жанрларының зур өч төркемгә бүләләр:

1) Хәбәри жанрлар

2) Аналитик жанрлар

3) Әдәби-публистик жанрлар.

1 .Хәбәри(магүлүмәти)төркем.

А) Бер генә вакыйга яисә факт турында сөйләүче кыска язма. Аның алдында торган бурыч - яктыртыла торган вакыйга яисә фактның зур әһәмияткә ия булуы. Хәбәрче вакыйгаларны алар булган көнне үк, фикер һәм тәэсирләр онытылганчы, язарга тиеш. Язманың күләме җыйнак, теле аңлаешлы, гади булсын.

Ә) Репортаж. Ул,кагыйдә буларак,эш-хәрәкәткә, динамикага бай булган вакыйгадан языла. Әйтик, юрт ярышыннан, иген басуыннан, завод цехыннан. Репортажның үзәгендә авторның

“мин” аның үзәтүләре,вакыйгалары хәрәкәттә тасфирлавы ята. Ягъни репортаж язучы үзенең күргәннәрен юхси кичерешләре аша үткәреп, хәрәкәтне күрсәтеп яза. Репортажлар төрле зур һәм әһәмиятле акыйгалардан, яңалыклардан да турыдан-туры языла.
Б) Хисап, ягни отчет. Төрле корылтай, утырыш, киңәшмә,митинг һ.б турында кыскача хисап ягни отчет бирү. Кыска гына булса да күп белүне сорый. Монда вакыйга барышын, исем-фамилияне (вазифаларны, чыгышларны төгәл күрсәтергә кирәк. Бу чарадагы чыгышларны үз кулына ала алсаң яисә диктофон куллансаң бигрәк тә әйбәт. Хисап жанры балалар газета-журналларында киң кулланыла. Әйтик төрле фестивальләр, очрашулар, кичәләр, бәйгеләр, олимпиадалар турында хисап язып була.
В) Интервью. Журналистның берәр мөһим мәсьәлә,вакыйга турында бу чараларда турыдан-туры катнашкан кеше белән иҗади әңгәрмә коруы. Аңа бу вакыйганы тулырак ачыклый торган сораулар бирүе, шул хакта укучыларга да язуы. Зур әзерлек, кешеләр белән мөнәсәбәткә керүдә осталык, тапкырлык, сорауларны дөрес куя белү сәләте сорый торган жанр.

Уку елы барышында менә бу жанрлар турында укучыларга киң мәгълүмат бирергә, аңлатырга, һәр жанр буенча өйгә эшләр биреп, яздырып карарга, кимчелекләрне күрсәтергә, киңәшләр бирергә. Уңышлы язылган материалның вакытлы матбугатька тәкъдим итәргә.
7. Поэтик букча. Үз гомерендә шигырь язып карамаган кеше юктыр. Бу тематик бүлектә шигырь язу техникасы турында аңлату. Балаларга шигъри үлчәмнәр турында төшенчә бирү.) Ак шигырь. Икеюллыклар. Эпиграммалар. Мадригал.Күренекле шагыйрьләрнең әсәрләр ен анализлап карарга. Яздырып карарга, кимчелекләрне күрсәтергә, киңәшләр бирергә. Уңышлы язылган материалны вакытлы матбугатькә тәкъдим итәргә.
8. Проза әсәрләре. Әкият ничек языла. Чын һәм ялган әкиятләр. Әкият төрләре (Хайваннар турында,тылсымлы экиятләр,көнкуреш экиятләре)
9. Район һәм республика күләмендә оештырылган иҗади конкурсларда катнашу.
Уку елы барышында журналистлар,язучылар,әдәби эшлеклеләр белән очрашулар,кичәләр оештырыла. Арча районы территориясендәге музейларга экскурсияләр.

10. .Йомгаклау дәресе Иҗат итү формасында уздырыла.

**2 нче уку елы планы**

| | Тема | барлыгы | теория | практика | контроль |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш. Кабатлау | 4 | - | 0 | Сорашу |
| 2 | Журналистика жанрлары | 26 | 6 | 20 | Язмаларны яклау |
| 3 | Публицистик жанрлар | 34 | 6 | 28 | Әсәр яклау |
| 4 | Проза | 30 | 4 | 26 | Әсәр яклау |
| 5 | Экскурсияләр. Очрашулар. Кичәләр. | 16 | | 16 | Чыгыш ясау |
| 6 | Мониторинг | 2 | | 2 | Презентация |
| 7 | Конкурслар | 4 | 4 | | Чыгыш ясау |
| 8 | Газета чыгару | 18 | 18 | | Тәкбирләү |
| 9 | Журналистикада аналитик жанрлар | 4 | | 4 | Әңгәмә |
| 10 | Йомгаклау. Белемнәрне тикшерү | 6 | | 4 | Әсәр яклау |
| | | 144 | | | |

**2нче уку елы программасы эчтәлеге**

1. Кереш дәрес. Кабатлау

Бу уку елында катлаулыга барып, журналистика жанрларын өйрәнүне дәвам итү.

2. Факт һәм вакыйганың асылына төшенеп, тормыштагы кайбер күренешләрнең сәбәпләрен белергә тели икән, хәбәрче-журналист аналитик жанр куллана:

А) Корреспонденция вакыйгаларга, куренешләргә булдыра алганча анализ ясап, сәбәпләрен ачарга тырышып языла. Конкрет бер мәсьәләгә туктала, урынга барып, мәсьәләне тикшерә, сәбәпләрен ачыклый, киләчәкне күзаллый. Күп вакыт сарыф ителә.

Б) Мәкалә. Корреспонденциягә охшаш, әмма киңрәк колачта, төрле мәсьәләләрдән чыгып гомумиләштерүләр ясала, анализ тагын да тирән ясап языла. Монда инде журналист үз фикерен әйтә, чагыштырулар ясый, мәсьәләләрне чишү юлларын да тәкъдим итә. Мәкалә күп материал туплап, аларны өйрәнеп, вакыт һәм хезмәт куеп языла.

Укучыларга кимчелекләрне курсәтергә, киңәшләр бирергә. Уңышлы язылган материалны вакытлы матбугатка тәкъдим итәргә.

3. Проза әсәрләре. Хикәяләр ничек языла. Тәмамланган уйны белдереп, вакыйга бер генә туры сызык буенча үстерелә. Композиция һәм сюжет. Балалар язган хикәяләрне анализлау.

Парча- тормыштагы күренешләргә тирәнтен бәя биреп язылган прозаик әсәр.

4. Драма - эпик әсәр, персонажлар сәхнәдә мөстәкыйль чыгыш ясыйлар, тамашачы үзе анализ ясый. Комедия, трагедия. Аңлатма бирү. Балаларга скетч, пьеса яздырып карау.

5. Уку елы барышында журналистлар, язучылар, әдәби эшлеклеләр белән очрашулар, кичәләр оештырыла. Музейларга экскурсияләр

6. Иҗади конкурсларда актив катнашу.

7. Айга 1 тапкыр компьютер аша җыйнап “Мәктәп пульсы” газетасын чыгару.

8. Журналист һәм укучы арасындагы бәйләнеш турында түгәрәк өстәл артында сөйләшү.

9. Белемнәрне тикшерү

10. Йомгаклау дәресе. Иҗат фестивале формасында уздырыла.

**Программаны тормышка ашыру шартлары һәм көтелгән уңышлар.**

Программа түгәрәк җитәкчесеннән фәнни-педагогик әзерлеккә ия булуны таләп итә. Укытучының филология, тарих, журналистика, рәсем сәнгате буенча билгеле бер күләмдә белеме, сәләте, күнекмәләре булырга тиеш. Һәрдаим эзләнгәндә, бай материал туплап, белгечләр белән киңәшләшеп, аларны эшчәнлеккә җәлеп иткәндә, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Белем бирү программасы шактый катлаулы, шуңа күрә түгәрәккә йөрүче балаларның дәресләргә даими йөрүе кирәк. Эш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: теоретик материал һәр дәрестә гамәли эш белән ныгытылырга тиеш. Укучылар үз көчләре белән нәрсәдер иҗат итсәләр, язсалар, кызыксыну арта. Шуны истә тотып, программада гамәли дәресләр өстенлек итә.

Күрсәтмә материалны мультимедиа чаралары аша файдалану уңышлы. Ул дәресне җанлырак итә, педагогның эшен бермә-бер җиңеләйтә. Әлеге программаны тулысынча тормышка ашыру өчен берләшмә утырышлары үткәрелә торган кабинетка интернет челтәренә тоташкан компьютер, ноутбук, фотоаппарат, принтер кирәк.

Курс буенча методик эшкәртмәләрнең аз булуы эштә күп кыенлыклар тудыра. Программа авторы бу юнәлештә туктаусыз эзләнү алып бара.

Программа материалын уңышлы үзләштергән укучы түбәндәге белем һәм күнекмәләргә ия булырга тиеш:
- мәктәптә яки группада үткәрелгән чара турында хәбәр яза;
- ритм һәм рифманы иҗат эшендә дөрес итеп куллана;
- журналистикадагы жанр төрләрен һәм үзенчәлекләрен дөрес һәм урынлы файдалана ала;
- һәр эшендә пөхтәлеккә, язмаларының дөреслегенә ирешергә омтыла;
- журналистика барлыкка килү, үсеш тарихыннан хәбәрдар, хәзерге шартларда журналистикадагы үсеш тенденцияләре белән кызыксына, яңалыкларны вакытында белеп бара;
- сүзләрдән образ тудыра, художестволы чаралар ярдәмендә иҗат итә белә;
- үзе иҗат иткән шигырьне сәнгатьле итеп сөйли;
- үз милләтенең культурасы, сәнгате һәм әдәбияты белән горурлану хисләре кичерә;
- хәзерге татар әдәби телендә аралаша һәм сәхнәдән торып сөйли белә;
- иҗади бәйгеләрдә катнаша.

## ПРОГРАММАНЫҢ МАТЕРИАЛ ЯКТАН ҺӘМ ТЕХНИК ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕ.

Дәресләр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча 2нче номерлы урта гомуми белем мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесендә алып барыла.

ШУС бүлмәсе, укучылар өчен эш урыннары.

Техник чаралар: өстәлләр, урындыклыр, шкаф, компьютер, принтер, фотоаппарат.

**Информацион тәэмин ителеш.:**

1. Веселая журналистика для детей и взрослых: https://litnet.com/ru/reader/veselaya- zhurnalistika-dlya-detei-i-vzroslyh-b71360 (дата обращения 20.08.2023);
2. Стилистические особенности детских изданий: http://stud24.ru/journalism/stilisticheskie-osobennosti-teksta-detskih-izdanij/37580-116628-page1.html (дата обращения 20.08.2023);;
3. http://mediaalmanah.ru/upload/iblock/6c6/2011_2_5_kulchickaja.pdf (дата обращения 25.08.2023);
4. Журналистика в условиях мультимедийности http://www.journ.msu.ru/about/mediatrends/2045/ (дата обращения 25.08.2023);

### Аттестация формасы

Уку елы башында диагностика.
Агымдагы диагностика.
Арадаш диагностика – беренче яртыеллыкта, уку елы азагында.
Йомгаклау диагностикасы– программа үтелеп беткәч.

**Кулланылган әдәбият**


1. Агзамов Ф.А. Теория журналистики. Казань, Таткнигоиздат, 1982
2. Аналитические жанры газеты. Хрестоматия. – М.: Изд-во Московского ун-та, 1989.
3. Әдәбият белеме сүзлеге. (Төз.:Әхмәдуллин А.Г.) Казан: Татар, кит.нәшр., 1990.
4. Ворошилов В.В. Журналистика. Учебник. - С-Пб., 2001.
5. Гарифуллин В.З. Хәбәри жанрлар. - Казан, 1991.
6. Гарифуллин В.З. Үткен каләм, үткер күз. - Казан: Тат. кит. нәшр.,1995.
7. Гарифуллин В.З. Язар сүзең булса... - Казан, 2000.
8. Гарифуллин В.З. Вакытлы матбугатта жанрлар. - Казан, 2007.
9. Горохов В.М. Основы журналистского мастерства. - М., 1989.
10. Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1981.
11. Хөснимәрдәнов М. Х. Журналист осталыгы.- Казан: Тат. кит. нәшр.,1990.
12. Письмо Министерства образования и науки Российской Федерации от 14.12.2015 № 09-3564 «О внеурочной деятельности и реализации дополнительных общеобразовательных программ»
13. «Экспертиза программ дополнительного образования детей, внеурочной деятельности и элективных курсов» (приложение к журналу «Внешкольник» - Бюллетень «Региональный опыт развития воспитания и дополнительного образования детей и молодёжи» № 4, 2014 г.)
14. «Методические рекомендации по проектированию дополнительных общеразвивающих программ (включая разноуровневые программы)» (направлены письмом Департамента государственной политики в сфере воспитания детей и молодёжи Министерства образования и науки Российской Федерации от 18.11.2015 № 09-3242)
15. Приказ МОиН РТ № 1465/14 от 20 марта 2014 г. «Об утверждении Модельного стандарта качества муниципальной услуги по организации предоставления дополнительного образования детей в многопрофильных организациях дополнительного образования в новой реакции»
16. Приказ МОиН РТ № 2529/14 от 6 мая 2014 г. «Об утверждении Модельного стандарта качества муниципальной услуги по организации предоставления дополнительного образования детей в общеобразовательных организациях»
17. Положение об общеобразовательных общеразвивающих программах МБУ ДО «Дворец школьников» от 29.08.2016г.